СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**от «19» август 2022ел** **№ 55**

**“Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 23.04.2021 ел, № 19 карары белән расланган Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1.1. 5 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;»;

**1.2. 7 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«2. Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.»;

**1.3. 22 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«10. Гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында муниципаль берәмлек халкына алдан хәбәр итүне, шул исәптән аны "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән яки, әгәр җирле үзидарә органының үз эшчәнлеге турында мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектының яисә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында, муниципаль берәмлек халкы тарафыннан муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен, муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларда катнашуын, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне), кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, аларны рәсми сайтка бирү юлы белән алдан таныштыруны күздә тотарга тиеш;

**1.4. 22 статьяның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«12. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияләрне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән

расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читкә китүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары буенча, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану рөхсәт ителгән бер төрне башка төргә үзгәртү мәсьәләләре буенча, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланмаган очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә, гавами тыңлаулар яисә җәмәгать фикер алышулары үткәрелә.»;

**1.5. 42 статьяның 1 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«7) Россия Федерациясе гражданлыгы яки аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы тукталу, чит ил гражданлыгы (подданлыгы) булу яки яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерацисе гражданының яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документы булу»;

**1.6. 47 статьяның 1 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы яки аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы тукталу, чит ил гражданлыгы (подданлыгы) булу яки яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерацисе гражданының яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документы булу»;

**1.7. 51 статьяның 1 өлешенең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:**

«-җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;»;

**1.8. 91 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Җирлек башлыгы җирлекнең теркәлгән уставын, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставын, муниципаль уставка үзгәрешләр кертү турындагы муниципаль хокук актны, Россия Федерациясе дәүләт реестрына кертү турында хәбәрнамә кергәннән соң, "Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында" 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясының 6 өлеше нигезендә, җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау өчен түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1). Мифтәхетдинов Рәвис Шәрәфи улы -4 нче Яңа Кырлай сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2). Миндубаев Тәлгәт Җәүдәт улы -9 нчы Яңа Кырлай сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3). Заһидуллин Фаил Нурулла улы – 2 нче Яңа Кырлай сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

6. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутатларының Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата тәкъдимнәре эшче төркемгә 2022 елның 08 сентябренә кадәр кертелә дип билгеләргә.

7. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата гражданнар тәкъдимнәре эшче төркемгә, авторның Ф.И.А.и.,туган елы, адресы күрсәтелеп, ТР, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт адресы буенча кертелә дип билгеләргә.

8. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны 2022 елның 09 сентябренә 16.00 сәгатьтә Яңа Кырлай авыл җирлегендә билгеләргә.

9. Эшче төркемгә, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына карата Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, 2022 елның 20 сентябренә кадәр Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының
19.08.2022 ел, № 55
карарына 1 нче кушымта

**“Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча тәкъдимнәр язмача төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советына 422035, Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт адресы буенча кертелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Проектның төзәтмә кертелгән тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и.,адресы, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу турында гаризалар язма рәвештә яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 422035, Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм башлыгына карау өчен тапшырыла.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының
19.08.2022 ел, № 55
карарына 2 нче кушымта

**«Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру**
**ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын карау буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте, прокуратура органнары, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, белгечләр, кызыксынган затларны чакырып үткәрелергә мөмкин.

3. Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яшәүче һәркем катнашырга хокуклы.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Яңа Кырлай авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге башлыгы рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында гавами тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән Устав проектын эшләү буенча эшче төркем җитәкчесе чыгыш ясый.

9. Төп докладтан соң сүз гавами тыңлауларда катнашырга чакырылган катнашучыларга бирелә.

10. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

11. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары расланган регламент нигезендә дәвам итәргә тиеш.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар рәис рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга чыгыш ясаганнан соң сораулар бирергә хокуклы.

13. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14.Гавами тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны тыңлаулар үткәрелә торган бинадан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

17. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә җитәкче һәм секретариат әгъзалары имза сала һәм ул Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә гавами тыңлаулар секретариаты тарафыннан әзерләнә һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Гавами тыңлаулар уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ